**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

«21» ноябрь 2025 ел № 10

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында » 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

2026 елда Яңа Иглай авыл җирлегендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- Якты Күл торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Якты күл т. п. территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: М.И. Хәмидуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы М.И. Хәмидуллин